**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**V чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр., 17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**V созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина, дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**КАРАР**
14.11.2025 ел

**РЕШЕНИЕ**
№02-07

**Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советының 2018 елның 27 апрелендәге 28-10 номерлы «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы муниципаль милкенә караган, торышы канәгатьләнерлек булмаган Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән файдаланылмый торган мәдәни мирас объектлары өчен ташламалы аренда түләвен билгеләү тәртибен раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында" 2025 елның 16 маендагы 667 номерлы карары нигезендә Актаныш муниципаль районы Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советының 2018 елның 27 апрелендәге 28-10 номерлы «Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы муниципаль милкенә караган, торышы канәгатьләнерлек булмаган Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларының (тарихи һәм мәдәни ядкарьләренең) бердәм дәүләт реестрына кертелгән файдаланылмый торган мәдәни мирас объектлары өчен ташламалы аренда түләвен билгеләү тәртибен раслау турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 7 пунктның а пунктчасына «, шулай ук тиешле мәдәни мирас объектының дини билгеләнештәге мөлкәткә яисә «Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга тапшыру турында» Федераль законның 12 статьясындагы 1 өлешендә һәм (яисә) 5 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән мөлкәткә кагылмавы хакында» сүзләрен өстәргә;

1.2. 2 пунктта «Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән» сүзләрен «Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мәдәният ядкарьләре) турында» Федераль законда билгеләнгән» сүзләренә алмаштырырга;

1.3. Тәртипнең 6 пунктындагы 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мәдәни мирас объектын Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә торышы канәгатьләнерлек булмаган мәдәни мирас объектларына кертү".

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://aktanysh.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

Совет рәисе Л.Р.Зарипов